**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы**
**Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең**
**Туктар-Урдаласы торак пункты гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2024 нче елның 1 нче апреле № 1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең Туктар-Урдаласы торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы (29.11.2023 №1532 редакциясендә) карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән,Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, 2024 елның 1 апрелендә узган «Сез 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең Туктар-Урдаласы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» карарына һәм 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең Туктар-Урдаласы торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» карарына үзгәреш кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтерү белән килешәсезме:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Туктар-Урдаласы торак пунктында Вахитов, Октябрь урамнары буенча юлларга вак таш җәю, Туктар-Урдаласы торак пунктында Совет, Вахитов, Тукай, октябрь, Куйбышев урамнары юлларны кардан чистарту)

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 316 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 162.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 162 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең Туктар-Урдаласы торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлеге составына керүче Туктар-Урдаласы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дерес дип танырга.

2. Сез 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең Туктар-Урдаласы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» карарына һәм 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең Туктар-Урдаласы торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» карарына үзгәреш кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтерү белән килешәсезме:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Туктар-Урдаласы торак пунктында Вахитов, Октябрь урамнары буенча юлларга вак таш җәю, Туктар-Урдаласы торак пунктында Совет, Вахитов, Тукай, октябрь, Куйбышев урамнары юлларны кардан чистарту)

кабул ителгән дип.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Туктар-Урдаласы авылы, Совет урамы, 98 йорт, административ бинада , Совет урамы, 103 йорт, Мәдәният йорты бинасында, Карагай авылында Тельман урамындагы МФЦ бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Туктар-Урдаласы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы

Г.Ә.Әхмәтова